**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 13 декабря 2013 года г. Казань **№** 3-8/э

***“Татарстан Республикасы җирендә ҖЧҖ “Энерготехснаб” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларны билгеләү турында” 14.12.2012 №3-11/э Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында***

“Электр энергетикасы турында” 26.03.2003 №35-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Электроэнергетика өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) билгеләү” 29.12.2011 №1178 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм “Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясе бәяләрен һәм җайга салынучы тарифларны билгеләү өлкәсендә методик киңәшләрне раслау хакында” 06.08.2004 №20-э/2 Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең боерыгы һәм “Тулай керемне озак сроклы индексацияләү ысулын кулланып, электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен тарифларны исәпләүдә методик киңәшләрне раслау хакында” 17.02.2012 №98-э, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы җирендә ҖЧҖ “Энерготехснаб” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында үзара хисап тоту өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару өчен, индивидуаль тарифларны билгеләү турында” 14.12.2012 №3-11/э Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2, 3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Әлеге карарның 4 кушымтасына таянып ҖЧҖ “Энерготехснаб” өчен 2013-2015 елларга озак сроклы җайга салу параметырларын билгеләргә.

3. Әлеге карарның 5 кушымтасына таянып ҖЧҖ “Энерготехснаб” өчен озак сроклы җайга салу кирәкле тулай керемне билгеләргә;

4 пунктны көчен югалткан дип исәпләргә;

2 нче кушымта текстын 1 нче кушымтага нигезләнеп яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымта текстын 2 нче кушымтага нигезләнеп яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымта текстын 3 нче кушымтага нигезләнеп яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына 1нче кушымта
13 декабрь 2013 ел. № 3-8/э

2014 елның 1 гыйнварыннан алып 2014 елның 30 июненә кадәр һәм 2014 елның 1 июленнән алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр, ҖЧҖ “Энерготехснаб” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында үзара хисап тоту өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару өчен индивидуаль тарифлар

(ӨБС исәпкә алынмаган)

| Челтәр оешманың исеме | 2014 елның 1 гыйнварыннан алып 2014 елның 30 июненә кадәр | | | 2014 елның 1 июленнән алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | Электр челтәрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | сум./кВт·ай | сум./кВт·сг | сум./кВт·сг | сум./кВт·ай | сум./кВт·сг | сум./кВт·сг |
| ҖЧҖ «Энерготехснаб» - ААҖ «Челтәр компаниясе» | 543,47174 | 0,06656 | 0,84422 | 496,76670 | 0,07259 | 0,78342 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына 2нче кушымта
13 декабрь 2013 ел № 3-8/э

2013-2015 елларда «Энерготехснаб» ҖЧҖның озак сроклы җайга салу параметырлары.

(ӨБС исәпкә алынмаган))

| Татарстан Республикасы челтәр оешманың исеме | Ел | Контролләнгән чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Контролләнгән чыгымнарның файдалылык индексы | Контролләнгән чыгымнарның активларның санына карап сыгылмалык коэффициенты | Электр энергиясенең технологик чыгымнар (югалтулар) күләме | Сатылган товарның (хезмәт күрсәтүнең) ышанычлылыгы | Сатылган товарның (хезмәт күрсәтүнең) сыйфаты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | млн.сум | % | % | млн.кВт·сг | | |
| ҖЧҖ «Энерготехснаб» | 2013 | 3,86 | 1 | 75 | 0,25 | 0,076 | 0,762 |
| | 2014 | × | 1 | 75 | 0,2238 | 0,076 | 0,762 |
| | 2015 | × | 1 | 75 | 0,2238 | 0,076 | 0,762 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
13 декабрь 2013 ел № 3-8/э

Озак сроклы җайлау периодында (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча)
ҖЧЖ «Энерготехснаб» челтәр оешмасының кирәкле тулай кереме

| Татарстан Республикасы челтәр оешманың исеме | Ел | Кирәкле тулай керем (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|
| | | мең.сум |
| ҖЧЖ «Энерготехснаб» | 2013 | 5112,98 |
| | 2014 | 5112,98 |
| | 2015 | 5583,50 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге